# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге составына керүче Иске Урыссу торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

21 ноябрь 2023 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2023 елның 21 ноябрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Иске Урыссу торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, I төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, Бөек Ватан сугышында катнашучы тол калган хатыннардан тыш, 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә сез ризамы:

- Иске Урыссу торак пунктында Елга урамы, 1 Май урамы буенча юлларны норматив хәлгә китерү (төзү, реконструкцияләү, асфальтлау, ремонтлау, вак таш җәю, төзелеш материаллары сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Хәтер скверы территориясенә хезмәт күрсәтү (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- авыл эчендәге юлларны карап тоту (грейдерлау, юлларны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- зиратта хуҗалык инвентары өчен бина төзү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- милли Сабантуй бәйрәмен үткәрү урынын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)”.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 561 катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә 283 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

- «ӘЙЕ» позициясе өчен җыенда 273 кеше тавыш бирде;
- «ЮК» позициясе өчен җыенда катнашкан 10 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәге карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Иске Урыссу торак пунктында халык җыенын узды дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. 2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Иске Урыссу торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, I төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, Бөек Ватан сугышында катнашучы тол калган хатыннардан тыш, 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә сез ризамы:

- Иске Урыссу торак пунктында Елга урамы, 1 Май урамы буенча юлларны норматив хәлгә китерү (төзү, реконструкцияләү, асфальтлау, ремонтлау, вак таш җәю,

төзелеш материаллары сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Хәтер скверы территориясенә хезмәт күрсәтү (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- авыл эчендәге юлларны карап тоту (грейдерлау, юлларны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- зиратта хуҗалык инвентары өчен бина төзү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- милли Сабантуй бәйрәмен үткәрү урынын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)” буенча сорауны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Урыссу авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга мөмкин: http://jutaza.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Урыссу авыл җирлеге башлыгы Ф.Г. Әминова